ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Зеленодольск шәһәре** **КАРАР**

**26.08.2026** **№2975**

Зеленодольск районы Башкарма комитетының «2020 - 2026 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 06 июлендәге 1219 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 08 августындагы 2372 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» 1710 номерлы карары белән расланган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» 1050 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт программаларының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү" дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында» 2024 елның 11 октябрендәге 877 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Зеленодольск районы Башкарма комитетының «2020 - 2026 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 06 июлендәге 1219 номерлы (2024 елның 08 августындагы 2372 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – карар) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның исемендәге «2020-2026 елларга» сүзләрен «2020-2030 елларга» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. карарның 1 нче пунктындагы «2020-2026 елларга» сүзләрен «2020-2030 елларга» сүзләре белән алыштырырга;

1.3. «2020-2026 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программа» карарындагы кушымтага үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарны 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4. «2020-2026 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программаны гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәсенең 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасы белән тулыландырырга:

«г) әлеге Программада Программада катнашу турында гариза бирү датасына кадәр кимендә 5 ел даими Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче яшь гаиләләр катнаша ала»;

1.5. Яшь гаиләләрне торакка мохтаҗ итеп тану өчен кирәкле документлар исемлегендә үзгәрешләр кертергә һәм аны әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкчесе З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 августындагы
2975 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 06 июлендәге
1219 номерлы карарына (2024 елның 08 августындагы 2372 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән)
Кушымта

**«2020-2030 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»**
**муниципаль программа**

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | «2020-2030 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программа (алга таба – Программа); |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында»гы 1710 номерлы карары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү»Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы 1050 номерлы карары;<br>«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 888 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 11 октябрендәге «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында» 877 номерлы карары; |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| Программаның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |

<table>
<tr><td>Программаның координаторы</td><td>«Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты » МКУ</td></tr>
<tr><td>Программаның төп максаты</td><td>Билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак проблемасын хәл итүдә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү</td></tr>
<tr><td>Программаның төп бурычлары</td><td>- программада катнашучы яшь гаиләләргә стандарт торак сатып алуга яисә стандарт индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләүләр бирүне тәэмин итү;<br>– яшь гаиләләрнең торак сатып алуга яисә индивидуаль торак төзүгә үз акчаларын, банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән ипотека торак кредитлары һәм заемнары бирүче оешмаларның өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру;</td></tr>
<tr><td>Программаның төп чараларын башкаручылар</td><td>- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре;<br>- стандарт торак бирү буенча вәкаләтле оешмалар;<br>- федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә сайлап алынган банклар</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2020 – 2030 еллар</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>- билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;<br>- федераль бюджет акчалары;<br>- Зеленодольск муниципаль районының җирле бюджеты акчалары;<br>-яшь гаиләләргә торак урын сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә кредитлар һәм заемнар, шул исәптән ипотека торак кредитлары бирүче кредит оешмаларының һәм башка оешмаларның акчалары;<br>- сатып алына торган торак урыны яки индивидуаль торак йорт төзелеше бәясен өлешчә түләү өчен файдаланыла торган яшь гаиләләр акчалары.<br>Программаны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның факттагы күләме дәүләт заказчысы - Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан бүлү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.<br>Яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары.
<table>
<tr><td rowspan="2">Финансла<br>у<br>чыганакла<br>ры</td><td colspan="6">Программаны гамәлгә ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>20<br>20</td><td>2021</td><td>2022</td><td>2023</td><td>2024</td><td>2025</td></tr>
<tr><td>Муниципа<br>ль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>54224,</td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 73 |
| Федераль бюджет | - | 175375,73 | 1399642,17 | 1340706,34 | 1851136,70 | 1271690,91 |
| Республика бюджеты | - | 843693,37 | 3886536,63 | 5117121,26 | 5523014,09 | 4096609,09 |
| Башка чыганаклар | - | 1892556,90 | 9817189,00 | 11993108,40 | 13694851,47 | 10070403,07 |
| Барлыгы | - | 2911626,00 | 15103367,80 | 18450936,00 | 21069002,26 | 15492927,80 |

| Финанслау чыганаклары | Программаны гамәлгә ашыру еллары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 | Гамәлгә ашыру чорында барлыгы |
| Муниципаль бюджет | 56216,16 | 28799,00 | 28834,00 | - | - | 168073,89 |
| Федераль бюджет | 1128849,28 | 753762,07 | 754687,38 | - | - | 8675850,58 |
| Республика бюджеты | 4436550,72 | 2097337,93 | 2099912,62 | - | - | 28100775,71 |
| Башка чыганаклар | 10440144,30 | 5348383,86 | 5354948,86 | - | - | 68611585,86 |
| Барлыгы | 16061760,46 | 8228282,86 | 8238382,86 | - | - | 105556286,04 |

| | |
|---|---|
| Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Программа чараларын уңышлы үтәү 2020 - 2030 елларда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итәргә, шулай ук түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- торак өлкәсенә ипотека буенча торак кредитлары һәм заемнары бирүче банкларның һәм башка оешмаларның өстәмә финанс чараларын, гражданнарның үз акчаларын җәлеп итү;<br>- җәмгыятьтә уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;<br>- гаилә мөнәсәбәтләрен ныгыту һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелек дәрәҗәсен киметү;<br>- ипотека торак кредитлау системасын үстерү; |

| | |
|---|---|
| | - торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме формаларын киңәйтү һәм яшь гаиләләр өчен торак алу мөмкинлеген арттыру.<br>Торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләрнең гомуми саны турыдан-туры Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау күләмнәреннән бәйле. |
| Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү ел саен «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ тарафыннан үткәрелә.<br>Программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ тарафыннан әзерләнә һәм хисаптан соң килүче елның 1 мартына кадәр раслау өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.<br>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре буенча, чираттагы финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында карар проектын керткән көнгә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, Зеленодольск муниципаль районы Советына программаны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елыннан башлап кыскарту яисә Программаны гамәлгә ашыруны вакытыннан алда туктату турында тәкъдимнәр кертә. |

**I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә, шул исәптән Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларга гомуми характеристика**

Яшь гаиләләр нигездә үз гомерләрендә беренче тапкыр торак сатып алучылар булып торалар, димәк, ипотека кредиты алганда актив буларак кулланылырга мөмкин булган торак милке юк, шулай ук башлангыч кертемне түләү өчен акча тупларга мөмкинлеге дә булмый. Шул ук вакытта халыкның әлеге категориясе квалификация күтәрелгән саен хезмәт хакы артуның яхшы перспективаларына ия, һәм торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме алар өчен киләчәктә һөнәри үсешкә яхшы этәргеч булып тора.

Торак проблемасын хәл иткәндә яшь гаиләләргә ярдәм күрсәтү халыкның бу актив өлеше өчен тотрыклы тормыш шартларының нигезе булачак, республикада демографик вәзгыятьнең яхшыруына йогынты ясаячак. Торак проблемасын хәл итү мөмкинлеге, шул исәптән ипотека кредиты яки займ акчаларын җәлеп итеп, яшьләр өчен хезмәт хакын үстерү максатларында хезмәт эшчәнлегенең сыйфатын, квалификация дәрәҗәсен күтәрүгә этәргеч бирәчәк. Яшь гражданнарның торак проблемасын хәл итү халыкның икътисадый актив катламын формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме формаларын киңәйтү, шул исәптән Программаны гамәлгә ашыру механизмы буенча да, яшь гаиләләрнең торак алу мөмкинлеген арттыруга йогынты ясаячак.

**II. Программаның максатлары, бурычлары, принциплары һәм гамәлгә ашыру сроклары**

Программа Татарстан Республикасында Милли проектның өстенлекле юнәлешләренең берсен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән, ул гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алуда яисә индивидуаль торак йорт төзүдә дәүләт ярдәме системасын үстерүне күздә тота.

Программаның максаты-билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак проблемасын хәл итүдә дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын күрсәтү.

Программаның бурычлары:

- Программада катнашучы яшь гаиләләргә стандарт торак сатып алуга яисә стандарт индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләүләр (алга таба - социаль түләүләр) бирүне тәэмин итү;

- яшь гаиләләрнең торак сатып алу яисә индивидуаль торак төзү өчен үз акчаларын, кредит һәм торак кредитлары һәм заемнары, шул исәптән ипотека кредитлары бирә торган башка оешмаларның өстәмә финанс акчаларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Программада катнашучы яшь гаиләләр стандарт торак сатып алу өчен вәкаләтле оешмаларга мөрәҗәгать итә ала.

Программаны гамәлгә ашыруның төп принциплары түбәндәгеләр:

- яшь гаиләләрнеңПрограммада ирекле катнашуы;

- закон нигезендә яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

- яшь гаиләнең социаль түләү күләменнән артыграк өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) хакын түләү өчен җитәрлек акчалары булу;

- яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга Программа кысаларында федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан һәм (яисә) җирле бюджетлардан бирелә торган акчалар исәбеннән ярдәм алуга үз хокукларын бер генә тапкыр гамәлгә ашыру мөмкинлеге.

Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүне күздә тоткан программада яки теләсә кайсы башка программада (ярдәмче программада) катнашуны сайлап алу хокукы яшь гаиләгә бирелә.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2020 - 2030 еллар.

## III. Программа чаралары системасы

Программа чаралары системасы федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла.

Федераль һәм региональ дәрәҗәләрдәге оештыру чаралары "Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү" федераль дәүләт программасы составына керә торган "Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" ярдәмче программа һәм "Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү " дәүләт программасының "Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү"  ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында оештыру чаралары түбәндәгеләрне күздә тота:

- законда билгеләнгән тәртиптә яшь гаиләләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

- үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен норматив-хокукый актлар кабул итү;

- Программада катнашучы яшь гаиләләрне исәпкә алуны оештыру;

- социаль түләүләр алуга яшь гаиләләр исемлекләрен ел саен төзү;

- Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган акчалар күләмен ел саен билгеләү;

- Программаның максатларын һәм бурычларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итү;

- яшь гаиләләргә билгеләнгән тәртиптә торак сатып алу өчен таныклыклар тапшыру;

- социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ЕГИССО) торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм буенча һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштыруны тәэмин итү;

Шулай ук үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль дәрәҗәдә оештыру чаралары түбәндәгеләрне күздә тота:

- программада катнашучылар турында мәгълүматларның мәгълүмати-аналитик базасын формалаштыру;

- программа чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын бүлеп бирүгә заявка төзү;

- Программаны гамәлгә ашыру барышын контрольдә тоту;

- массакүләм мәгълүмат чараларында программаны тормышка ашыру максатларын, бурычларын һәм нәтиҗәләрен яктыртуны тәэмин итү;

- программаны тормышка ашыру мониторингын үткәрү, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыкка - республика программасының дәүләт заказчысына тапшыру өчен мәгълүмати-аналитик һәм хисап материаллары әзерләү.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның төп чыганаклары булып тора:

- билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары:

- федераль бюджет акчалары;

- Зеленодольск муниципаль районының җирле бюджеты акчалары;

-яшь гаиләләргә торак урын сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә кредитлар һәм заемнар, шул исәптән ипотека торак кредитлары бирүче кредит оешмаларының һәм башка оешмаларның акчалары;

- сатып алына торган торак урыны яки шәхси торак йорт төзелеше бәясен өлешчә түләү өчен файдаланыла торган яшь гаиләләр акчалары.

Программаны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның факттагы күләме дәүләт заказчысы - Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан бүлү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру механизмы Программада катнашучы яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүнең өстәмә чараларын күрсәтүне күздә тота.

Торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү  Программага кушымтада китерелгән кагыйдәләр нигезендә бирелә һәм файдаланыла.

Социаль түләүне бирүнең шарты булып яшь гаиләнең торак сатып алуга (төзелешкә) кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе) буенча, шул исәптән ипотека торак шартнамәсе буенча алынган, торак урын төзү яки сатып алуга түләү өчен кирәкле өстәмә акчалары булу тора. Өстәмә акча сыйфатында яшь гаилә шулай ук ана (гаилә) капиталы акчаларын (акчаларның бер өлешен) файдаланырга мөмкин.

Яшь гаиләгә социаль түләүне җиткерү механизмы сыйфатында торак урын сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләүне алу хокукы турындагы таныклык (алга таба - таныклык) кулланылачак, аны яшь гаиләнең программаны гамәлгә ашыруда катнашуы турында карар кабул иткән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тапшыра.Алынган таныклыкның хуҗасы тарафыннан социаль түләүләр бирүгә каралган акчаларга хезмәт күрсәтү өчен Программаның дәүләт

заказчысы тарафыннан сайлап алынган банкка тапшырыла, анда яшь гаилә әгъзасы исеменә социаль түләүне күчерү өчен билгеләнгән банк счеты ачыла. Таныклыкның хуҗасы булган яшь гаилә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан банк белән банк счеты килешүе төзи.

МКУ «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» - программа координаторы түбәндәге эшләрне башкара:

- программада катнашучыларның эшен координацияләү;
- программаны гамәлгә ашыруны методик яктан тәэмин итү;
- республика программасының дәүләт заказчысы, вәкаләтле оешмалар, банк белән хезмәттәшлекне тәэмин итү;
- Зеленодольск муниципаль районының республика программасында катнашу өчен заявкасын яклау;
- программа чараларының нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм бәяләү;
- республика программасының дәүләт заказчысына тапшыру өчен мәгълүмати-аналитик һәм хисап материалларын әзерләү.

## VI. Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү бюджет акчаларын кулланып торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләр санынннан торган индикатор нигезендә гамәлгә башкарылачак.

Программаны гамәлгә ашыру һәм аны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчаларын куллану нәтиҗәлелеге, Программада каралган критерийларны һәм индикаторларны исәпкә алып, тәэмин ителәчәк.

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары төп чаралар киселешендә кушылган таблицада китерелгән.

## VII. Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ тарафыннан ел саен үткәрелә.

Программаны гамәлгә ашыру барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 2018 елның 26. июнендәге 1341 номерлы карары белән расланган Тәртип буенча әзерләнә һәм хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр раслау өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре буенча, чираттагы финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында карар проектын керткән көнгә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, Зеленодольск муниципаль районы Советына программаны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елыннан башлап кыскарту яисә Программаны гамәлгә ашыруны вакытыннан алда туктату турында тәкъдимнәр кертә.

**«2020-2030 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау**

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ярдәмче программаның аталышы | Төп чараларның атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 |
| Билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак проблемасын хәл итүдә өстәмә дәүләт | Программада катнашучы яшь гаиләләргә стандарт торак сатып алуга яисә стандарт индивидуаль торак йорт төзүгә | «2020-2030 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль програм | Программада катнашучы яшь гаиләләргә стандарт торак сатып алуга яисә стандарт индивидуаль торак йорт төзүгә | - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Татарстан Республи | 2020-2030 | Хисап елында ярдәмче программа кысаларында торак урыннары алган һәм торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләр саны, берәмлек | - | 1 | 3 | 3 | 4 | 2 | 2 | 1 | 1 | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ярдәме чаралары күрсәтү | социаль түләүләр бирүне тәэмин итү | ма | социаль түләүләр бирүне тәэмин итү | касы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре; - стандарт торак бирү буенча вәкаләтле оешмалар; - федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә сайлап алынган банклар | | | | | | | | | | | | | |

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ярдәмче программаның аталышы | Төп чараларның атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 |
| Билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак проблемасын хәл итүдә өстәмә | Программада катнашучы яшь гаиләләргә стандарт торак сатып алуга яисә стандарт индивидуаль торак йорт төзүгә социаль | «2020-2030 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программа | Программада катнашучы яшь гаиләләргә стандарт торак сатып алуга яисә стандарт индивидуаль торак йорт төзүгә социаль | - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Татарстан Республикасы Зеленодольск | 2020-2030 | Хисап елында ярдәмче программа кысаларында торак урыннары алган һәм торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләр саны, берәмлек | - | Барлыгы: 2911626,00<br>Бюджет РФ: 175375,73<br>Бюджет ТР: 843693,37<br>Бюджет ЗМР: - | Барлыгы: 15103367,80<br>Бюджет РФ: 1399642,17<br>Бюджет ТР: 3886536,63<br>Бюджет ЗМР: - | Барлыгы: 18450936,00<br>Бюджет РФ: 1340706,34<br>Бюджет ТР: 5117121,26<br>Бюджет ЗМР: - | Барлыгы: 21069002,26<br>Бюджет РФ: 1851136,70<br>Бюджет ТР: 5523014,09<br>Бюджет ЗМР: - | Барлыгы: 15492927,80<br>Бюджет РФ: 1271690,91<br>Бюджет ТР: 4096609,09<br>Бюджет ЗМР: 54224 | Барлыгы: 16061760,46<br>Бюджет РФ: 1128849,28<br>Бюджет ТР: 4436550,72<br>Бюджет ЗМР: 56216 | Барлыгы: 8228282,86<br>Бюджет РФ: 753762,07<br>Бюджет ТР: 2097337,93<br>Бюджет ЗМР: 28799,00 | Барлыгы: 8238382,86<br>Бюджет РФ: 754687,38<br>Бюджет ТР: 2099912,62<br>Бюджет ЗМР: 28834,00 | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү | түләүләр бирүне тәэмин итү | | түләүләр бирүне тәэмин итү | муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре; - стандарт торак бирү буенча вәкаләтле оешмалар; - федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә | | | | Яшь гаиләләр акчалары: 1892556,90 | Яшь гаиләләр акчалары: 9817189,00 | Яшь гаиләләр акчалары: 11993108,40 | Яшь гаиләләр акчалары: 13694851,47 | ,73 Яшь гаиләләр акчалары: 10070403,07 | ,16 Яшь гаиләләр акчалары: 10440144,30 | Яшь гаиләләр акчалары: 5348383,86 | Яшь гаиләләр акчалары: 5354948,86 | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | сайлап алынган банклар | | | | | | | | | | | | |

2 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты тарафыннан 2026
елның 26 августындагы 2975 номерлы
карарына
«
«2020 - 2026 елларга Зеленодольск
муниципаль районында яшь гаиләләрне
торак белән тәэмин итү» муниципаль
программаны гамәлгә ашыру
кысаларында яшь гаиләләргә торак
сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр
бирү кагыйдәләренә
2 нче ушымта

**Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану өчен һәм бирелә торган социаль түләү күләменнән артыграк өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) хакын түләү өчен җитәрлек керемнәре йә башка акчалары булганда кирәкле документлар исемлеге**

Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану өчен һәм бирелә торган социаль түләү күләменнән артыграк өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) хакын түләү өчен җитәрлек керемнәре йә башка акчалары булганда түбәндәге документлар тапшырыла:

1) кредит алырга мөмкинлек бирә торган керемнәр яисә бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлештә торакның исәп (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек булган башка акчалар булу турында гариза;

2) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар күчермәләре (паспорт, бала туу турында таныклык, хәрби билет һ. б.);

3) язылышу турында (аерылышу турында) таныклык күчермәсе;

4) торак урынының гомуми мәйданын күрсәтеп, финанс-лицевой счет;

5) теркәлү урыны буенча урнашкан торак урынга, шулай ук милектәге башка торак урыннарга соңгы 5 елда хокук билгели торган документларның күчермәләре (социаль наем шартнамәсе, хосусыйлаштыру шартнамәсе, сату-алу шартнамәсе, бүләк бирү шартнамәсе, күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәткә хокуклар һәм алар белән алыш-бирешләр реестрыннан өземтә) индивидуаль торак төзелеше объектларында яшәүчеләргә әлеге объектка техник паспорт;

7) 1991 елдан башлап элеккеге теркәлү урыннарыннан – адресын, теркәлү, теркәлүдән төшү вакытларын, гомуми мәйданын һәм яшәүчеләр санын күрсәтеп, архив белешмәләре;

10) 2000 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча, Техник инвентаризация бюросыннан гражданинга теркәлгән барлык капиталь төзелеш объектларының булуын (булмавын) раслый торган, теркәлгән күчемсез милекнең булуы яки булмавы турындагы белешмә – барлык яшь гаилә әгъзаларына;;

9) ИНН күчермәләре – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

10) гаиләнең һәр әгъзасының индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүен раслый торган документ күчермәсе;

11) гражданның эш урыны, аның вазыйфасы турында белешмәләрне үз эченә алган оешма җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан имзаланган һәм оешма мөһере белән таныкланган оешма реквизитлары белән эшләү урыныннан белешмә -

яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

12) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (оешма җитәкчесе яки кадрлар бүлеге башлыгы имзасы белән расланган барлык битләр, "хәзерге вакытта эшли" тамгасы белән) - яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

13) алдагы һәм агымдагы еллар өчен хезмәт хакы турында белешмә (яшәү адресын күрсәтеп, 2-НДФЛ формасы буенча) - яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

14) стипендия (студентлар өчен), пособиеләр, пенсияләр, алимент (әгәр булса) алу турында белешмәләр;

15) яшь гаиләнең кертеме булуын раслаучы документлар (яшь гаиләнең бер әгъзасына рәсмиләштерелгән банк кертеме булуын раслаучы банк документы күчермәсе, яки яшь гаилә әгъзаларының тупланма счетыннан өземтә) һәм (яки) кредит оешмасының иргә-хатынга яки аларның берсенә, максималь күләмен күрсәтеп, кредит (бурычка) бирү мөмкинлеге турындагы документы;

16) алдагы календарь ел өчен һәм агымдагы календарь елның узган хисап чоры өчен салым органы тамгасы белән декларация (эшмәкәр өчен) яисә вакытлы керем түләүгә күчкән эшмәкәрләр өчен вакытлы керемгә салым түләү турында таныклык (соңгы алты ай өчен).

17) яшь гаиләдәге ир яисә хатынның берсе яисә икесе дә йә тулы булмаган яшь гаиләдә әти-әнинең берсе махсус хәрби операциядә катнашуын раслый торган документның күчермәсе (булган очракта);

18)салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы түләнгән булу турында белешмә;

19) яшь гаилә әгъзаларының Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының боерыгы белән расланган форма буенча яшь гаиләдәге балигъ булган әгъзаларының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.